| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге Советы |

Р Е Ш Е Н И Е — К А Р А Р

17 июнь 2024 ел — №117

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәткә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау турында» Бөрешле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча Структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында” карары белән расланган “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең «12688» күләмендәге вазыйфаи окладларының күләмен «13323» сумга алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәткә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 14 февралендәге 77 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

2.1. 1 нче кушымтада “17390” санын “18260” саннары белән алыштырырга; “9,26” саннарын “12,86” саннары белән, “9,18” саннарын “12,77” саннары белән алыштырырга;

2.2. Карарның 6 кушымтасында «унсигез процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга

2.3. Карарның 16 кушымтасында 1 пунктның 3 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга htpp://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Бөрешле авыл җирлеге” бүлегендә урнаштырырга:http://mendeleevsk.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Бөрешле авыл җирлеге Советы башлыгы — Л.А. Смирнова